| | |
|---|---|
| ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 23 октябре Лениногорск №211

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәре Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән куллану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәре Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән куллану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 15статьяны түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункт белән тулыландырырга: «1.1. Әгәр мондый кире кагу рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларының бер яки берничә чик параметрларын бер тапкыр үзгәртү, конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү максатларында, ун процентан артмаган очракта, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

б) 4нче өлештә беренче җөмләне "әлеге статьяның 1_1 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш" сүзләре белән тулыландырырга;

в) 32 статьяның 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территориаль зоналар чикләре һәр җир участогының бер территориаль зонага каравы таләбенә җавап бирергә тиеш. Төрле территориаль зоналарда урнашкан берничә җир кишәрлегеннән бер җир кишәрлеген формалаштыру рөхсәт ителми. Территориаль зоналар, кагыйдә буларак, бер җир участогына карата билгеләнми.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – “Лениногорские вести” газетында бастырырга, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов